БАКЧА ҖИМЕШЕ
Авылда артып калганнан да акча ясап була

> 2

АВЫЛ ИМАМЫ
«ВТ» укучыларының саладагы дин әһелләре турында язмалары

> 3

МӘДӘНИЯТ ХАКЫНА
Ирада Әюпова журналистлар белән мәдәният киләчәге турында сөйләште

> 4

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ
«Бернинди мохтаҗлыгың булмаса да, нәрсәдер сорарга кирәк»

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 91 (28864) | Чәршәмбе | 29 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

Сәрия МИФТАХОВА

ДҮРТНЕ БИШ ИТӘРЛӘРМЕ?

Вузлардагы вазгыять

Белгечләр хәзер ике баскычлы белем бирү системасын, ягъни бакалавриат һәм магистратураны иң уңышсыз реформа дип таный. Дәүләт Думасында депутатлар, ректорлар белән бергәләп, вузларның киләчәге турында фикер алышты. Дөрес, Болонья системасыннан бөтенләй баш тартырга җыенмыйлар. Белгечләрне ничек дөрес әзерләргә?

Югары белем бирү системасына әлеге үзгәреш безнең илдә 2003 елда кертелгән иде. Студент югары уку йортында дүрт ел белеп алып, аннары ике ел магистратурада укый ала дигән сүз бу. Еш кына бакалаврларны чиле-пешле белгечләр дип тә атыйлар. Янәсе, эшеңнең остасы булу өчен биш ел укырга кирәк. Яңа система кертелгәннән бирле шушы сүзләрне ишетеп килдек һәм тора-бара моңа ияләштек кебек. 19 елдан соң исә боз кузгалды. Көнбатыштан кертелгән чикләүләр сәбәпле, әлеге системага күчү ялгыш булган икән, дип терсәк тешли башладык. Россия фән һәм югары белем министры Валерий Фальков әйтүенчә, белгечләрне югары дәрәҗәдә әзерләү өчен, дүрт еллык бакалавриат кына аз. Эш бирүчеләр дә моны җитәрлек дип санамый. Бакалавриаттан соң яшь белгеч еш кына магистратураны башка юнәлеш буенча сайлый. Нәтиҗәдә икесенең берсе яраксыз булып чыга. Магистратура әзерлекне ныгыту буларак уйланылган иде, әмма бакалавриатны тәмамлаган студентлар эшкә урнашырга яки белем бирүне кичке формада дәвам иттерергә тырыша, ягъни тиешле дәрәҗәдә белем ала алмый.

Министр белдергәнчә, югары белем илкүләм икътисадны үстерүне һәм студентлар өчен күбрәк мөмкинлек тудыруны күздә тотарга тиеш. Безгә киләчәкне күздә тотып эшләүче белгечләр кирәк. Инженерлар әзерләү, технологик эшмәкәрлекне үстерүне алга җибәрү мөһим. «Моңа кадәр булган тәҗрибәне югалтмыйча, яхшысына таянып, алга баруны дәвам иттерергә, чит стандартларга яраклашуны, чит ил тәҗрибәсенә сукырларча таянуны туктатырга кирәк. Болонья процессыннан чыксак та, чит илләрдә Россия дипломнарын хөкүмәтара килешүләр нигезендә таныячаклар», – ди Валерий Фальков.

Депутат Сергей Миронов фикеренчә, югары белем алу бөтен кешегә дә бушлай булырга, стипендия аз дигәндә дә, минималь хезмәт хакы күләмендә булырга тиеш. БДИның файдасын күрми ул. «БДИ төбәкләрдәге яшьләргә чит шәһәрләрдә белем алу мөмкинлеген бирүне күздә тота. Тик Мәскәү, Санкт-Петербургта бары тик хәлле гаиләләрдәге балалар гына укый ала. Әлеге шәһәрләрдә укып, төбәкләргә кем кире кайткан? Бармак белән генә санарлык бит. Алар Көнбатышка китә. Уңышсыз бакалаврларны кем өчен әзерлибез? Безгә биш еллык укыту системасына кайтырга кирәк», – ди депутат.

КПРФ фракциясе рәисе Геннадий Зюганов та үз фикерен әйтте. «Заводны җимереп була, мин сезгә аны ике елда төзим. Әмма белем бирү системасын җимерү кеше өчен – гомерлек җәрәхәт. Яңасын төзергә дәүләткә, ким дигәндә, 20 ел кирәк», – ди ул.

sstu.ru

Ике баскычлы укытуга карата Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты ректоры Рәшит Низамовның фикерен белештек.

– Кичә Дәүләт Думасында узган парламент тыңлауларында төрле тәкъдимнәр булды. Без инде күп еллар Болонья системасы буенча эшләдек. Аны бөтенләй бетереп атарга ярамый, уңай яклары да, тискәреләре дә бар. Безгә шул тәҗрибәне истә тотып, үзебезнең яңа системаны булдырырга кирәк. Әмма биш ел укыту иң дөрес система булган. Шуңа күрә ракетасын, очкычларын да эшләп чыгардык. Бер депутат бик дөрес әйтте: без, фәнни хезмәтләрне чит илләрдә чыга торган журналларда бастырып, шуның белән мактанабыз. Моны ул мәгарифтә колониаль сәясәт дип атый, – ди Рәшит Низамов. – Университетта бакалавриат та, магистратура да бар. Икесен кушсаң, совет заманындагы инженер килеп чыга дип укытабыз. Тик бездә магистратурада журналист та, юрист та килеп укый ала. Бу бик дөрес нәрсә түгел инде. Бездә белгеч бер этабын укыган икән, икенчесендә дә укырга тиеш. Берәүдән дә калышмыйбыз анысы, архитектура, төзелештә әйдәп барабыз. Тик кешене өйрәтергә кирәк. Кулына көрәк тоттырып, эшлә, дип чыгарып җибәреп кенә булмый. Студентларны тәрбияләргә, дөньяга карашын булдырырга булышырга тиешбез.

Татарстанның элеккеге мәгариф һәм фән министры Васил Гайфуллин фикеренчә, ике баскычлы укыту үзен акламады.

– Заманында укытучыларны биш ел эчендә бик яхшы итеп әзерләдек. Дүрт елда гына сыйфатлы белем бирү мөмкин түгел. Магистратура белән дә ерак барып булмый. Барыбер фәнни хезмәткәр булып чыкмыйлар. БДИның да бер файдасын күрмим. Студентны белеп, тыңлап кабул итүдән дә яхшысы юк. Элеккеге укыту системасына кайтырга кирәк, – диде ул.

Студентларның күбесе, бакалавр дипломы алып, укуларын магистратурада дәвам иттерергә теләми. Акча эшлисе бар, монысы да җиткән, диләр. Кайберләре бөтенләй башка юнәлештә хезмәт куя. Әнә КФУда бакалавриатны тарих юнәлеше буенча тәмамлаган Рәхилә Шиһапова да шундыйлардан. Бүген ул – SMM белгече. «Мәктәпкә барып укытырга теләгем юк. Магистратурага да керергә җыенмыйм. Акча эшләр өчен анда бару кирәкми. Хәзер яшьләрне күбрәк акча кызыктыра. Әгәр белемеңне арттырырга телисең икән, берәр курста укырга була бит. Нигә хафаланырга?» – ди Рәхилә.

Үзмәшгульләр арткан

Ел башыннан бирле Татарстанда эшмәкәрләр саны, 6353 кешегә артып, 166765кә җиткән. Республика Премьер-министры урынбасары – икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов әйтүенчә, үзмәшгульләрне санамаганда, кече һәм урта бизнеста эшләүчеләр саны ел башындагы дәрәҗәдә (610317 кеше) сакланып калган. Бу уңай күренешнең сәбәбе, беренчедән, республика сәнәгать паркларын алга таба үстерүгә, икенчедән, федераль һәм республика күләмендәге ярдәм чараларыннан максималь дәрәҗәдә файдалануга, өченчедән, җитештерелә торган продукцияне сату базарларын киңәйтүгә бәйле. Бу атнада финанс ярдәме программалары буенча барлыгы 39 гариза (112 миллион сумга) тапшырылган. Шуның 26сы (89,8 миллион сумлык) хупланган.

Казанга килгәндә, үзмәшгульләрне кертеп, кече һәм урта эшмәкәрләр саны 148,5 меңгә җиткән. Бу – узган елның июнь аендагы белән чагыштырганда 28,1 меңгә яки 23 процентка күбрәк. Бигрәк тә үзмәшгульләр сафы ишәйгән – 60 процентка. Татарстан башкаласында хәзер аларның саны 67 меңгә җиткән.

Чүптән кәнфит ясаячаклар

Россиядә икенчел чималны эшкәртүгә кире кайтырга ниятлиләр. Моның өчен чүпне аерып җыю һәм аны эшкәртеп, хуҗалык әйләнешенә кертү күздә тотыла. Дәүләт Думасы әнә шундый закон проектын икенче укылышта кабул иткән. Документка «икенчел ресурслар» һәм «икенчел чимал» дигән төшенчәләр кертелгән. Икенчел ресурслар калдыкларның төре буларак билгеләнә. Аларны 2030 елдан соң җиргә күмүне тыю планлаштырыла. Чүпне аерып җыю яки аны җыю пунктына илтеп тапшыру һәркем өчен мәҗбүри булачак. Закон проекты нигезендә, оешмалар һәм эшмәкәрләр үз калдыкларын мөстәкыйль утильләштерәчәк. Аның төп максаты – чүп полигоннарына калдыклар чыгаруны киметү.

Сабан туена көтәләр

Мордовиядә Бөтенроссия авыл Сабан туе узачак. Бәйрәм 2 июльдә Аксен авылында үткәрелә. Ләмбрә районы хакимияте башлыгы Юрий Голов әйтүенчә, Сабантуйга республиканың барлык районнарыннан, шулай ук Россиянең башка төбәкләреннән 30 меңнән артык кунак килүе көтелә.

Бәйрәм 84 гектар мәйдандагы кырда узачак. Биредә төп мәйдан, атлар чабышы өчен ипподром, көрәш мәйданчыгы оештырылачак, милли аш-сулардан торган 78 туклану ноктасы эшләячәк. Сабантуйга Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Мордовия башлыгы Артем Здуновның килүе көтелә.

Юрий Голов сүзләренә караганда, җиңүчеләр өчен иң зур бүләк – ике автомобиль әзерләп куелган. Берсе – Татарстан Президенты исеменнән милли көрәш батырына, икенчесе Мордовия Республикасы башлыгы исеменнән ат чабышында җиңүчегә тапшырылачак.

Корбан чалу урыннары билгеле

Татарстан Диния нәзарәтендә Корбан бәйрәме көннәрендә терлек чалу урыннарын билгеләгәннәр. Республикада бу максаттагы 39 мәйданчык исемлеге нәзарәт сайтында урнаштырылган. Бәйрәм чаралары мәчетләрдә узачак, корбан чалу йоласы коронавируска каршы чараларны үтәү нигезендә башкарылачак. Корбан чалу, бәйрәм намазыннан соң башланып, 3 көн дәвам итәчәк.

Моннан тыш Диния нәзарәтенең Казыйлар һәм Голәмәләр шурасы быел корбан чалу өчен нисаб күләмен билгеләгән. Ул 32 мең сум тәшкил итә. Бурычын түләгәннән соң, тормыш кирәк-ярагы чыгымнарыннан соң шуның кадәр акчасы артып калган кеше корбан чалырга тиеш дигән сүз.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яшәргә өйрәнәбез

Мәшәкате азрак

1 июльдән Татарстанда яңа салым режимы гамәлгә керәчәк. Бу яңалык урта һәм кече эшмәкәрләргә кагыла. Салымның автоматлаштырылган әлеге системасы 2027 елга кадәр гамәлдә булачак. Яңа мөмкинлектән 18 меңләп эшмәкәр файдаланыр дип көтелә.

Салым федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе башлыгы Марат Сафиуллин сүзләренә караганда, республикадан тыш әлеге системаны Мәскәүдә, Мәскәү һәм Калуга өлкәләрендә дә сынап караячаклар. Салым түләүнең әлеге ысулын сайлаган эшмәкәрләр иминият фондына түләүләрдән, хисап бирүләрдән азат булачак. Ник дигәндә, салым органы, оешманың касса аппаратыннан алынган мәгълүматлар нигезендә салым күләмен шәхсән үзе исәпләячәк.



Салым органы белән хезмәттәшлек тә эшмәкәрнең Салым федераль хезмәте сайтындагы шәхси бите аша барачак. Салым органы һәр айның 1 нче числосына кадәр анда эшмәкәр түләргә тиешле салым күләмен исәпләп җибәрә, ул исә, үз чиратында, 7 көн эчендә әлеге мәгълүматларны расларга яки төзәтмә кертергә тиеш була. Салым органы ул җибәргән хатны раслагач, эшмәкәргә һәр айның 25 нче числосына кадәр билгеләнгән салымны түлисе генә кала. Дөрес, мәшәкате азрак булса да, бу юлны сайлаган очракта салым проценты югарырак булачак. Ул керемнең 8 процентын тәшкил итәчәк.

– Бу система эшмәкәрләргә эшне җиңеләйтү өчен кертелде. Бигрәк тә салым хезмәте белән эш иткәндә авырлыклар килеп чыкмасын өчен кирәк бу. Аннары яңа системага күчкән очракта хисапчының да кирәге калмый. Керем-чыгымнарны, салым күләмен билгеләүне махсус кредит оешмасы яки банк алып барачак. Бу, үз чиратында, эшмәкәрнең чыгымнары да азмы-күпме кими дигән сүз, – дип сөйләде журналистларга идарә башлыгы.

Салым түләүнең яңа системасыннан штатта ким дигәндә 5 кеше исәпләнгән, 60 миллион сумга кадәр табыш алган оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр файдалана ала. Эшчеләргә хезмәт хакының банк хисабы аша түләнүе дә шарт. Салым түләүнең яңа ысулыннан файдалану өчен Салым федераль хезмәте сайтындагы шәхси бит аша гариза тапшырырга кирәк. Быелның 1 июленнән генә шәхси эшмәкәр яки физик зат булып теркәлүчеләр моны 30 көннән дә соңга калмыйча башкарырга тиеш.

Сүз уңаеннан, Марат Сафиуллин сүзләренә караганда, республикада үзмәшгуль булып теркәлүчеләр саны да арта бара. Бүген аларның сафы 200 меңнән арткан. «Татарстанда һәр атна саен бер меңгә якын кеше үзмәшгуль булып теркәлә», – ди идарә башлыгы.

Сүзгә-сүз

Валентина МАТВИЕНКО, Федерация Советы Рәисе:

Мәктәпләрдә тарих дәресләрен арттыру турында уйларга тәкъдим итәм. Коры лекцияләр, тарихи даталарны ятлап кына чын ватанпәрвәр үстереп булмый. Бала бөтен күңеле белән нинди бөек илдә яшәвен, ата-бабаларының Россияне үстерү һәм яклау өчен күп көч куйганын тоярга тиеш. Моның өчен балаларга мөмкин кадәр күбрәк илебезнең мөһим тарихи урыннарын күрсәтергә кирәк.

РОССИЯДӘ – МӘДӘНИ ЯЛ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләрнең театрга мөнәсәбәтен ачыклаган. Сораштырудан билгеле булганча, мәдәни ял итүне ир-атларга караганда хатын-кызлар күбрәк хуп күрә икән.



63% >> беркайчан да булган юк, йә елына бер тапкыр

29% >> елга берничә тапкыр театрга барам

6% >> аена ике тапкыр барып кайтам



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

НАТО КӨЧЕН АРТТЫРА,

яки Кызыл флаглар җилфердәгәндә

Бу юллар сишәмбе көнне Испания башкаласы Мадридта НАТО блогына кергән ил лидерларының саммиты башланыр алдыннан языла. Төньяк атлантик альянска кергән дәүләтләрдә исә хәл җиңел түгел, вазгыять бик катлаулы. Халыклар тормыштан бер дә риза түгел. Сул идеяләр көчәя, Көнбатыш буйлап яңадан «коммунизм шәүләсе» йөри башлый. Маркс һәм Энгельс тарафыннан унтугызынчы гасыр уртасында ук язылган «Коммунистлар партиясе манифесты»н хәзерге яшьләр белми. «Манифест» исә «Европа буйлап шәүлә йөри – коммунизм шәүләсе» дигән сүзләр белән башланып китә. Егерменче гасыр ахырларында – яңа меңьеллык башында өченче дөнья илләрен рәхимсез сыгу хисабына үзендә туклык булдырган Европа илләрендә «шәүлә» онытылган, алар үзләрен горур рәвештә «алтын миллиард» дип атый башлаганнар иде. Ул эпоха узып бара, Көнбатыш яңадан социаль тетрәнүләр чорына аяк басты. НАТО саммиты алдыннан гына Мадридта «НАТОга контрсаммит» оештырылды, анда катнашучылар проблемаларны хәрби көч белән түгел, дипломатик ысуллар белән хәл итәргә чакырдылар. Хәрби блок лидерлары килер алдыннан исә испан башкаласында гадәттән тыш саклык чаралары кертелде. Якшәмбе көнне Мадридта меңләгән демонстрант, саммитка протест белдереп, урамнарга чыкты, урак һәм чүкеч төшерелгән кызыл флаглар җилфердәде. Бу юлларны укучы, автор Россия пропагандасы тәэсирендә яза, дип уйлар инде. Юк, мәгълүматны көнбатышлыларның үзләреннән – Россиядә тыелган һәм бикләнгән «Америка тавышы»ннан алам. Сайты бикләнсә дә, Telegram каналы иркен эшли аның.

Төньяк атлантик блок илләре лидерлары очрашуының монысы «тарихи» дип бәяләнде. Альянсның генсегы Йенс Столтенберг кабул ителәчәк документны «стратегик көндәшлек һәм иминлеккә янаулар үсү эпохасы»на әзерлек дип бәяләде. Генсек сүзләре буенча, хәрби блок «фундаменталь трансформация» процессында. «Трансформация» дигәне хәрби куәтне арттыруны һәм Россиянең көнбатыш чикләрендә зур хәрби көч туплауны күз алдында тота. Испан газетасы El País мәгълүматларына караганда, НАТО Европадагы көчләрен кимендә ике тапкыр арттырырга, яңа хәрби берләшмәләрне катлаулы корал белән коралландырырга һәм аларга хәрәкәт итүдә автономия бирергә җыена.

Шимбә көнне НАТОның Брюссельдәге штаб-квартирасында бу хакта сөйләшү булды инде. Рәсми булмаган рәвештә «Мадрид концепциясе» дип йөртелә торган документ тикшерелде. «Мадрид концепциясе» Россия белән араны өзә, Мәскәү турыдан-туры «иминлеккә янаучы» дип игълан ителә. Польшаның вице-премьеры Ярослав Качиньский Россия чигендә даими рәвештә 75 мең НАТО солдатын тотарга (илләрнең үз гаскәрләре бу санга керми), хәтта АКШның атом-төш коралын Польшада урнаштырырга чакыра. Салкын сугыш елларыннан соң бу дәрәҗәдәге киеренкелек булганы юк иде. Әлбәттә, борчылу тудыра, күңелдә шом уята бу хәлләр.

Россиядә

ДЕФОЛТ БУЛМАГАН ДЕФОЛТ

27 июньдә Bloomberg мәгълүмат агентлыгы дүшәмбегә каршы төндә Россиядә соңгы йөз ел эчендә беренче тапкыр дефолт булуын игълан итте. 1918 елда большевиклар патша Россиясенең тышкы әҗәтен түләүдән баш тартканнан соң, бер тапкыр да Мәскәүгә бәйле андый хәл туганы юк иде. Дөрес, 1998 елда без, россиялеләр, техник дефолтның ни икәнен бер тапкыр үз җилкәбездә татыдык. Ул чакта хөкүмәт «ГКО» дип аталган әҗәт кәгазьләре буенча түләүләрне туктатты, чөнки түләргә акчасы юк иде. Безнең хәл бер көн эчендә начарайды: сумның курсы 4–5 тапкыр очсызланды, бәяләр күккә сикерде… Әмма бу атна башының «дефолт»ын без сизмәдек. Бәяләр дә үз урынында, сум, киресенчә, долларга карата ныгый, бернинди ажиотаж да, паника да юк.

Дефолт ук булып җитмәгән дефолт исә, көнбатышлылар күзлегеннән караганда, Мәскәүнең 27 майда ук еврооблигацияләр буенча тиешле чираттагы түләвен башкармау нәтиҗәсендә туды. Россия җитәкчелеге без түләүне башкардык, тиешле акча инвесторлар хисабына озатылды, алар анда барып җитмәгән икән, гаеп бездә түгел дигән позицияне алды. Чынлап та, Финанс министрлыгы алдан ук тиешле акчаны Милли хисап депозитариена күчергән, әмма санкцияләр нәтиҗәсендә россияле һәм европалы депозитарийлар арасындагы күпер җимерелгән һәм акча тиешле адреска барып җитмәгән. Әмма шулай да кайбер инвесторлар, аерым алганда кулларында Россия евробондларын тоткан тайваньлылар, түләүләрне алганнар.

Мәсьәләнең техник ягын без шул урында калдырып торыйк. Тиешле квалификациягә ия банкир булмасаң, схемаларга төшенү мөмкин түгел. Россиядә әҗәтләрне түләргә акча бар, әмма түләргә мөмкинлек бирмиләр. Мәскәү инвесторларга «килегез дә акчагызны алыгыз» дип тора, тегеләре моны эшли алмый. Хәтта Bloomberg та вазгыятьне «символик дефолт» дип бәяли. Аннан соң дефолтны мәгълүмат агентлыклары түгел, рейтинг агентлыклары игълан итә: «Фәлән дәүләтнең түләргә хәленнән килми, аңа бүтән әҗәт бирмәгез», – диләр. Санкцияләр исә рейтинг агентлыкларына Россиягә бәя бирүне тыялар. Шулай да бер агентлык Мәскәүнең дефолтын игълан итте инде. Хәтта дефолт рәсми рәвештә барлык дәүләтләр тарафыннан, шул исәптән Кремль тарафыннан да бар дип игълан ителсә дә, бүгенге вазгыятьтә безнең өчен моның бернинди куркынычы да юк. Россиягә болай да әҗәт бирмиләр, чөнки санкцияләр белән тыелган. Паниканы һәм ажиотажны без февраль ахыры – март башында ук үттек инде. Буласы булды. Доллар да сикерде, бәяләр дә үсте.

Россия өчен куркыныч башка яктан яный. Россиялеләр банклардан алган кредитларын түли алмабыз дип курка. Бары тик бурычлыларның 23 процент чамасы гына бирәчәген кайтарып бирә алуына ышана. Дөрес, күпчелек кредитын түләп бара әлегә, әмма эшсез калырбыз да, барысы да җимерелер, дип шомлана. Аларның бу шиге урынсыз ук түгел, чөнки илдә электр энергиясен куллану кими. Бу – зур сәнәгать предприятиеләре җитештерүне киметә дигән күрсәткеч.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Татарстанда авыллардагы почта бүлекләрен яңарта башладылар. Әлеге программаны Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча гамәлгә ашыралар. 2022 ел азагына кадәр республикада «Бердәм Россия» партиясе ярдәмендә 15 почта бүлекчәсен төзекләндерү ниятләнә. Бу җәһәттән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Россия Почтасы» генераль директоры Максим Акимов белән очрашу үткәрде.

Очрашуда сүз республикада почта бүлекләре челтәрен үстерү, һәркем файдалана алырлык хезмәтләр исемлеген киңәйтү һәм төбәкнең логистик мөмкинлекләрен тормышка ашыру турында фикер алыштылар. Шулай ук Казан аэропортында транспорт хабын үстерү һәм бонд склады (аерым салым һәм таможня режимы булган ирекле сәүдә зоналары. – **Ред**.) ачу турында да сөйләштеләр.

– Авыл җирлекләрендә почта бүлекләре – иң мөһим социаль объектларның берсе. Татарстанда 1111 почта бүлеге һәм 8216 почта хезмәткәре эшли. Аларның эше нәтиҗәсендә безнең халык вакытында хат-посылкалар алыша, кирәк-яраклар сатып ала, торак-коммуналь хезмәтләр өчен түли, пенсия ала. Логистика мәсьәләсе аерым игътибарга лаек, бу юнәлештә эшләргә әзер, – диде Президент.

Сүз уңаеннан, 1111 почта бүлекчәсенең 851е авыл җирлекләрендә урнашкан. Почта хезмәтләреннән ай саен миллионга якын кеше файдалана.

– Татарстан – икътисади үзәк, монда таләпчән клиентлар яши, логистика җәһәтеннән дә таләпләре зурдан. Шуңа да Татарстан яңа, инновацион хезмәтләрне сынау мәйданчыгы булып тора да, – диде очрашуда Максим Акимов.

***

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Кызыл Хач» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасы рәисе Павел Савчук белән очрашты.

Республика җитәкчесе Павел Савчукны оешманың 155 еллыгы белән котлады. Президент әйтүенчә, хәзерге вакытта оешма уникаль кешеләрне берләштерә. Бу кешеләрнең тормыш фәлсәфәсе дә шәфкатьлелек һәм авыр минутларда башкаларга ярдәм итүгә корылган. «Сез һәрвакыт бәла-казалар һәм гадәттән тыш хәлләр зонасына беренчеләрдән киләсез, ярдәмгә әзерсез», – дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов.

Очрашуда ике арадагы хезмәттәшлек, уртак проектларны гамәлгә ашыру, шулай ук гуманитар оешманың Татарстан бүлеген үстерү мәсьәләләре буенча фикер алыштылар.

tatarstan.ru

Максим Акимов (сулда) әйтүенчә, Татарстанда почта хезмәтенең мөмкинлекләрен арттырып була.

ӘҺӘМИЯТЛЕ ДАТА БЕЛӘН!

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Халыкара парламентаризм көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Кадерле татарстанлылар! Хөрмәтле коллегалар – барлык дәрәҗәдәге вәкиллекле хакимият органнары депутатлары! Сезне ихлас күңелдән Халыкара парламентаризм көне белән котлыйм! Ул глобаль тотрыклылыкны ныгытуга, иминлекне арттыруга һәм бөтен дөньяда кешеләрнең яшәү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән парламент дипломатиясе һәм парламентара хезмәттәшлекнең әһәмиятен ачык күрсәтә.

Бүгенге дәүләтләрнең сәяси системасында һәм конституциячел механизмнарында закон чыгару хакимияте аерым урын алып тора. Хәзерге көндә территориаль вәкиллекнең роле көчәя, чөнки нәкъ менә төбәк парламентлары, вәкиллекле җирле үзидарә органнары хакимиятне кешеләргә якынайту, халык мәнфәгатьләрен турыдан-туры яклау өчен куәтле инструмент булып тора.

Россиянең иң яңа дәүләтчелеге чорында ил парламентаризмы, хакимиятләр бүленү системасының аерылгысыз атрибуты һәм халык хакимиятенең ныклы нигезе буларак, олы юл узды. Илнең Төп Законына 2020 елда кабул ителгән төзәтмәләр Россия Федерациясе суверенитетын, аның халыкара мәйданда мәнфәгатьләрен яклау, шул исәптән парламент ярдәмендә дә, мөмкинлекләрен сизелерлек ныгытты, Федераль Собрание, төбәкләр һәм муниципалитетларның җаваплылыгын арттырды, тотрыклы һәм чынбарлыкка туры килә торган законнар булдыру өчен нигез салды. Дәүләтнең социаль функциясен алга таба да көчәйтү, уңайлы инвестицион һәм эшлекле мохит булдыру, гражданнар арасында тынычлык һәм милләтара татулыкны ныгыту өчен алшартлар тудырды.

Татарстан Республикасы, вәкиллекле демократиянең төп принципларын эзлекле рәвештә гамәлгә ашырып, үзгәрешләр һәм мөһим социаль-икътисади нәтиҗәләргә ирешү юлыннан нык адымнар белән бара. Парламентарийларыбыз эше нигезендә – актуаль проблемаларны тирәнтен анализлау һәм аларны хокукый җайга салу юлларын эзләү, халык белән ачык аралашу, гражданнар җәмгыяте институтлары һәм коммерциягә карамаган оешмалар, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек, үткәннәргә хөрмәт һәм традицияләргә тугрылык. Бу барлык дәрәҗәдәге (федераль, региональ һәм җирле) Татарстан депутатларының сайлаучылар алдында җаваплылыгын, шул исәптән очрашулар һәм сайлау кампанияләре барышында әйтелгән һәр вәгъдә, наказ яисә конструктив тәкъдимне вакытында үтәү җаваплылыгын, арттыра. Республиканың халык вәкилләре законнар базасын камилләштерү буенча актив һәм бердәм эш алып бара, төбәкнең динамик үсешенә, тормыш сыйфатын арттыруга, шәхеснең ирекле үсеше өчен уңайлы хокук мохите булдыруга юнәлдерелгән әһәмиятле норматив документлар кабул итә.

Хөрмәтле татарстанлылар! Халыкара парламентаризм көнендә Сезгә барыгызга да нык сәламәтлек, тынычлык, иминлек һәм иң изге теләкләр, ә барлык дәрәҗәдәге вәкиллекле хакимият органнары депутатларына актив һәм алга карап эш итүне һәм Ватаныбыз хакына парламент хезмәтендә зур уңышлар телим!

Заманы нинди – һөнәре шундый

«Яшьләргә һөнәр сайларга ярдәм итү эше системалы рәвештә алып барылырга тиеш». Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның «ТНВ» депутатлар төркеме белән «Татарстан – Яңа Гасыр» республика иҗтимагый хәрәкәте югары советының уртак утырышында әйткән сүзләре бу.

Парламент башлыгы оешмалар цифрлы үзгәрешләр кичергән чорда кадрлар әзерләү мәсьәләсенең аеруча актуаль булуын искәртте. «Цифрлаштыру – көндәшлеккә сәләтле икътисад үстерү, халыкның яшәү шартларын яхшыртуга йөз тоткан илләр таянган дөньякүләм үсеш юлы ул. Дүртенче технология революциясе, җитештерү юнәлешен үзгәртеп кенә калмыйча, хезмәт базарындагы үзгәрешләргә дә китерде», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт Советы Рәисе фикеренчә, килеп туган вазгыять шартларында кадрлар әзерләүгә дә яңа таләпләр куела. «Бүген эш бирүчеләргә югары белем алу турындагы диплом белән эш тәҗрибәсе генә җитми. Һөнәр яки белгечлектән тыш, бу юнәлештә алган күнекмәләр белән компетенцияләр дә мөһим булган чор җитте. Хезмәт базары бер төрле белгечлекләргә мохтаҗлык кичергәндә, уку йортлары башкаларын әзерләргә тиеш түгел», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Хәзерге вакытта Россия Хөкүмәте тарафыннан 2024 елга кадәр цифрлы икътисадны төп биш төрле юнәлештә үстерүнең максат-бурычларын билгеләгән «Цифрлы икътисад» илкүләм программасы булдырылган. Шушы программа кысасында каралган ун проект Татарстандагы Иннополис университетында гамәлгә ашырыла.

Фәрит Мөхәммәтшин хәзерге вакытта республиканың мәктәп, көллият һәм югары уку йортларында яшьләргә эшкә урнашырга ярдәм итүче махсус хезмәтләр эшләвен дә искәртте. «Иң мөһиме: бу эш системалы рәвештә алып барылырга тиеш. Мәктәп тәмамлаган бала теге яки бу белгечлекләрне тиешенчә күзаллап бетерми. Нәтиҗәдә, күп кенә студентлар беренче курста ук укуын ташлый яки вуздан соң үз белгечлеге буенча эшләми», – диде парламент башлыгы.

Дәүләт Советы Рәисе бу урында яшьләргә һөнәр сайларга ярдәм итүче махсус сайт һәм платформалар булдырырга кирәклеген дә искәртте. Утырыш барышында Фәрит Мөхәммәтшин республика һәм илдәге бүгенге вазгыятькә, шушы шартларда икътисадның ни рәвешле яшәвенә дә тукталды. «Килеп туган шартларда без бердәмлегебезне күрсәтергә тиеш», – диде парламент Рәисе.

Фәрит Мөхәммәтшин үз чыгышында 3 июль көнне «Татарстан – Яңа Гасыр» республика иҗтимагый хәрәкәте оешуга 23 ел тулуны да искәртте. «Бу хәрәкәт республиканың иҗтимагый тормышында актив катнаша. Бүген ул 110нан артык татарстанлыны, республиканың иң актив иҗтимагый көчләрен берләштерә. Эшчәнлекнең төп юнәлешләре буенча тырышлыкны алга таба да дәвам иттерергә кирәк», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Киңәшмәдә яшьләрне вакытлыча эшле итү, эш бирүче белән һөнәри уку йортлары арасында хезмәттәшлек мәсьәләләре турында да фикер алышты. Утырышта катнашучылар Татарстан Президенты белән республика хөкүмәтенә, башкарма хакимият органнарына оешмалар өчен кадрлар әзерләү һәм яшьләрне хезмәт базарына яраклаштыруга кагылышлы тәкъдимнәрдән торган резолюция дә кабул итте.

САТАР ӘЙБЕРЕҢ БУЛСА...

Авыл хәлләре

Никадәр генә зарлансак та, бүгенге заманда тәвәккәллеге, үткенлеге, теләге булган кешегә юктан да акча эшләргә мөмкинлекләр бар. Һәм аннан оста файдаланган кешеләр дә күп. «Акча аяк астында, аны иелеп алырга гына кирәк» дигән гыйбарәне тормыш девизы иткән андыйларга афәрин генә! Килешәсездер, бу кадәресенә теләк кенә түгел, сәләт тә кирәк. Ә менә анысы бөтен кешегә дә бирелмәгән. Калганнарга – авыл җирендә яшәп, үз хуҗалыгында җитештергән продукциянең үзеннән артканын кая куярга, нишләргә? Бүген сүзебез шул хакта.

Авыл турындагы сүзне берничек тә сөттән башламыйча булмый. Ни генә дисәк тә, күмәк хуҗалыкларга да, шәхси хуҗалыкларга да ел әйләнәсе акча кертә торган тармак шушы. Сөткә бәяләр авыл тормышы өчен лакмус кәгазе дисәң дә, арттыру булмас. Тормыш дәрәҗәсен күрсәтә, алай гына да түгел, билгели торган күрсәткеч ул. Сөткә бәяләр төште икән, авылда сыер асраучылар саны кими. Әнә берничә ел бәяләр тотрыклы тора – икешәр сыер асраучылар артты. Мин белә-белгәннән авылда бишәр-алтышар сыер асраучы юк иде, быел бар. Өчәрне асраучылар да берничә. Дөрес, бер бетергәннәр генә кабат сыер асрарга бик ашыкмый, бер онытылгач, шактый мәшәкатьле, проблемалы бу эшкә кабат тотынасы килмидер шул. Башка урында ничектер, бездә сөт җыйнауда беркайчан да өзеклек, проблема булмады. Ел әйләнәсе, көн дә йә иртән, йә кичен сөтне алып китәләр. Шәхси сөт җыючылар да бар. Бәяләр бер чама. Соңгы айларда безгә, мәсәлән, бер литр сөткә 31–33 сумнан исәп-хисап ясалган. Аена кырыгар мең сум, аннан да артыграк өстәмә акча алучылар бар. Тырыш хезмәт белән табылган акча бу.

Кемнәрдер сөтләрен моннан кыйммәткәрәк, пластик шешәләргә тутырып, аерым нокталарга тапшыра яки үзләре сата. Моннан берничә ел элек Балтач үзәгендә (урамда) үзләреннән арткан сөттер, йомырка, җиләк-җимеш, үсенте сатучыларга, сатар өчен ачык базар бар дип, ул урыннан җибәрергә дә тырышып карадылар. Әмма халык өчен дә көндәлек уңайлы булуын аңлаптыр, аларга да ирек бирелде. Дөрес, анда сатучылар күп түгел. Көн саен эшли торган ачык базарда да андыйларга урын җитәрлек.

Икмәк комбинаты территориясендә моннан берничә ел элек ачылган, пәнҗешәмбе көнне эшләгәнгә халыкта «Атна кич базары» дип йөртелүче базарга җитми берсе дә. Дөрес, мин анда сирәк керәм. Кергән саен гаҗәпләнеп чыгам. Анда инде иртәнге сәгатьләрдә үк сатучылар да, сатып алучылар да күп була. Сөт, авыл каймагы, эремчек, йомырка ише продукция сатучыларның үз клиентлары бар, диделәр. «Каймак өчен банканы бу базарга алып килеп бирәбез», – диючеләр дә, пластик савытлар белән генә алучылар да бар икән.

– Урыны да бик әйбәт, бу базарны көтеп торабыз, бер атнада да бармый калганым юк, – ди Балтачта яшәүче танышым Рәшит абый. – Бөтен нәрсә свежий була. Гади кешеләр сөт-ит ризыклары (үзләре каклаган каз, казылык, колбаса) алып килә. Анда бит аерым кешеләр генә түгел, эшмәкәрләр дә үз әйберләрен сата. Кукмарадан, Питрәчтән, Арчадан, Сабадан, Маридан, Нократ Аланыннан кадәр киләләр. Сайлап алырга мөмкинлек зур. Бәяләре кибеттәгедән әллә ни ким димәс идем, әмма барыбер бөтенесен чират торып алабыз.

Вакыйф Зәкиев

Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләрендә зурланган, чоры өчен бик данлыклы булган Чепья базары 62 ел өзеклектән соң кабат эшли башлады.

Бу базарның тәртибе шундый: керү өлешендә чеби-биби, тавык ише кош-корт сатыла, бер рәттә ашамлыклар, икенче якта кием-салым, араларында үсентеләр, агач-куакларга да урын табыла. Мәйданы киң, урыны уңайлы. Әллә ни катгый таләпләр юк.

– Бөтенесен әлеге базар урнашкан икмәк комбинаты җитәкчелеге контрольдә тота. Теләгән һәркем үз продукциясен сата ала. Биш-алты еллап эшли инде бу базар, ул үзе бер дөнья, өлкәннәр анда аралашыр өчен дә килә, – ди район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илшат Галимуллин. – Башта урын өчен акча алмадылар, хәзер үзебезнекеләрдән – 300, читләрдән бишәр йөз сум җыялар. Бу көннәрдә районда тагын бер базар – данлыклы Чепья базарын эшләтә башладык. Ул гомер-гомергә ял көнне эшләгән. Хәзер авыл кешесе ял көнне базарга чыгып сатасы килми. Уйлаштык та, бу базарны сишәмбе көнне билгеләргә булдык.

– Бүген базарның беренче көне, әле алты ноктада гына сату бара, халыкны ияләштерергә кирәк булачак, – ди әлеге җирлек башлыгы Азат Нотфуллин. – Менә базарда йөрим, халык сөт сорый, икенче базарга ук сөтен дә, башкасын да сатучылар артачак, билгеле. Әлегә урын өчен акча җыелмаячак. Безнең дә базарның урыны бик уңайлы, алга таба иске балалар бакчасы мәйданына да җәелергә ниятлибез. Өч ел буе хыялландык без бу базар турында. Сатып алучыларга да уңайлы, сатар әйберсе булган бу як авылларында яшәүчеләр өчен дә тагын бер мөмкинлек дигән сүз бит бу…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ИЛЛӘР ГИЗГӘН ИМАМ

Авыл өстендә, намазга чакырып, азан тавышы яңгырый. Күңелләрне уятып, рәхәт бер дулкын йөгереп үтә. Күңелгә бу моңлы, матур аһәңле тавышның хуҗасы үзе дә бер илаһи заттыр дигән уй керә. Авылдашларымның бәхетенә бу зат – шушы ук авылда туып-үскән, ямь-яшел болыннарда тәгәрәп уйнаган, шушы мәктәптә белем алган, бүген авылдашларының ихтирамын яулаган Шамил хәзрәт.

1997 елда Казаннан туган авылына, туган нигезенә кайтып төпләнә Шамил хәзрәт. Шул гомердән бирле бер көн калмый изге эшне башкара ул: авылдашлары һәм тирә-як авылда яшәүче мөселманнар күңеленә иман орлыклары сала. Шамил хәзрәтнең тормышы – һәркем өчен үрнәк.

Ул Арчаның Хәсәншәех авылында 1948 елның 21 сентябрендә дөньяга килгән. Әтисе Сәләхетдин углы Шиһабетдин – Бөек Ватан сугышы инвалиды. Сугыштан кайткач, Пөшәңгәр авылында туган Әхмәтгали кызы Гарифәбану белән гаилә корганнар... «Сабый чагым авылда үткән. Тормыш җиңел булмаган, кечкенә вакытымда мине тәрбияләргә әтинең бертуган сеңлесе Әлфинур апа булышкан. 1950 елда энем Камил, сеңлем Рәдифә, сеңлем Рәзинә, энем Данил дөньяга килгән. Шулай итеп без биш бала булганбыз. Әти-әни эштә: алар колхозның яшелчә бакчасында каравыл торганнар. Әтинең сугыш яралары һәрвакыт белгертеп торган, шуңа да сырхауханәләрдә күп ятарга туры килгән. Балалар тәрбиясе әни өстендә булган, без, апам Флера, зуррак балалар, аңа булышканыбыз әле дә хәтердә. Мәктәпкә барыр вакыт җиткәч, барлы-юклы уку кирәк-яракларын туплап, әнинең баш яулыгына төйнәп, Хәсәншәех башлангыч мәктәбенә 1 нче класска киткәнем дә хәтердә», – дип искә ала хәзрәт.

– Миндә алга таба да белем алу теләге көчле иде. Тик бу вакытта совхоздан җибәрмиләр. Шулай да, 1968 елда Казанга барып, 21 нче ГПТУга укырга кереп кайттым һәм шунда шомартучы-буяучы һөнәре буенча укый башладым. Училищены кызыл таныклык белән тәмамлагач, мине техникумга укырга җибәрделәр, әмма анда инде кабул итү тәмамланган иде. Шулай итеп, Казан фото-желатин заводына эшкә урнаштым. Кичләрен эштән буш арада, берәр үзешчән сәнгать түгәрәгенә йөреп булмасмы дип, мин Татарстанның Х еллыгы исемендәге мәдәният йортына киттем. Анда җыр түгәрәге дә, театр түгәрәге дә бар иде. Җыр түгәрәген Миңгол ага Галиев, театр түгәрәген Гөлсем исемле апа җитәкли. Мин икесенә дә йөри башладым. Миңгол абый миңа музыка училищесына барып карарга тәкъдим итте. 1971 елда имтиханнар тапшырып карарга булдым. Аллаһның рәхмәте белән, безне, ике татар егетен, кабул иттеләр. Икенче татар егете дигәнем Рөстәм Маликов иде. Шулай итеп, без студентлар булып киттек. Рөстәм белән дуслаштык, бөтен нәрсәбез уртак булды, группабыз да бик бердәм иде.

1975 елдан Шамил Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшли башлый. Шушы елларда беренче тапкыр чит илгә чыгу насыйп була аңа. Алар Тунистагы Бөтендөнья фольклор ансамбльләренең Карфаген фестивалендә катнаша, аннан ансамбль лауреат булып кайта. Ә 1979 елда Көнбатыш Африкада урнашкан Нигерия, Сенегал, Бенин дигән дәүләтләрдә чыгыш ясыйлар.

Шамил хәзрәт дин юлына аяк басуын болай аңлата:

– СССР вакытында Госконцерт, Росконцерт дигән оешмалар бар иде. Алар бөтен коллективлар өчен еллык маршрутларны билгеләп куялар, без шулар буенча эшләдек. Советлар Союзы буенча гастрольләргә йөрмәгән җир калмагандыр. 1981 нче елда микән, төгәл хәтерләмим, Чехословакиягә киттек, анда 15 көннән артык йөреп кайттык, – дип сөйли ул еллар хакында Шамил. Нәкъ менә шул елларда күңеле дингә тартыла башлый аның. «Күрше фатирда гаиләсе белән Рәйсә исемле апа яши иде. Хатыным Ләлә шушы апа белән аралаша башлады. Ул вакытта Рәйсә апа намаз укый иде инде. Рамазан ае җитте. Ләлә Рәйсә апа белән ураза тота башлады. Әкренләп, мин дә дини йолаларга тартыла башладым. Ләлә апагыз кодалый: «Әйдә, син дә», – ди. Шулай итеп, Болгар мәчетенә укырга йөри башладым. Ул вакытта остаз Барый Тулбаев исемле бабай иде. Ул безгә гарәп хәрефләрен өйрәтеп, Коръән уку серләренә төшендерә башлады. Икенче елда остазыбыз авырып китте. Мин Нурулла мәчетенә барып, Фәрит Кадыйров исемле хәзрәттә белем ала башладым, 2 ел укыдым. Ләлә апагыз Мәрҗани мәчетендә абыстайларда белем алды. Ул Рәшидә апа Исхакый, Нуркамал абыстай кебек көчле абыстайларда укыды.

Ул тагын бер сәфәрне аеруча җылылык белән искә ала:

– 1987 елда без Япониягә гастрольгә чыгып киттек. Поездда – Мәскәүгә, аннан самолетта – Владивостокка, Находка дигән порттан паром белән Йокогама дигән шәһәрнең портына килеп төштек. Бу илдә алган хатирәләр минем күңелемнән һичкайчан чыкмаслар. Бер ай 10 көн эчендә бик күп шәһәрләрдә, утрауларда булдык. Токиога килгәч, безне аның үзәгенә, күккә ашкан йортлар янына алып килделәр. Шуларның берсенең 86 нчы катына урнашкан күзәтү мәйданчыгына алып менделәр. Ул көнне томанлырак булуга карамастан, күренеш искитмәле булып хәтердә калган. Бер утрауга баргач, анда яшәүче халыкның милли бәйрәменә туры килдек. Без дә үзебезнең милли киемнәрне киеп, алар оештырган карнавалда катнаштык. Гастролебез бик уңышлы үтте, анда яшәүче татарлар белән таныштык, кунакка чакырдылар, онытылмаслык очрашу булды. Шулай итеп, төрле кызыклы вакыйгалар белән бәйләнеп, гастролебез тәмам булып, исән-сау туган илебезгә әйләнеп кайттык. Инде безнең бу вакытта дингә килүебез тирәнәйгән иде. Тормыш болай дәвам итә алмас, олыгаербыз дип уйладык та, ансамбльдән китәргә булдык. Язу җайланмалары эшләп чыгара торган заводка эшкә урнашып, яңа һөнәр үзләштереп, эшли башладык. Шушы заводта 10 ел эшләп, лаеклы ялга чыктык.

Авылда әниләре төп нигездә үзе генә калгач, алар Казандагы тормышларын калдырып, 1997 елда авылга кайталар. Авыл тормышы башлана. Гаилә мәчеткә йөри башлый.

– Бу вакытта мәчеттә имам булып авылның бик хөрмәтле кешесе Готыф хәзрәт тора иде. Аның белән күп эшләр башкардык: балаларны укыта башладык, экскурсияләргә йөрттек. Әлхәмдүлилләһ, мәчеттә икенче имамлыкны да алып бара башладым. Бу эшләрдә Готыф хәзрәтнең улы Әхмәтов Марат Готыф улының ярдәме бик зур иде. Готыф ага белән эшләү бик рәхәт иде, ул кешелекле, ярдәмчел, игелекле кеше иде. Тик 2004 елда Готыф ага вафат булды. Аннан соң авыл халкы мине беренче имам итеп сайлап куйды. Имамлыкны тулысы белән мин алып бара башладым.

Менә шундый тирән белемле, итагатьле, илләр гизгән, Ләлә ханым белән бергә зур хыялын – хаҗ кылуны Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән тормышка ашырган, яшәешен туган авылына, аның халкына багышлаган татар егете ул безнең авыл имамы. Аның шәкертләре арасында Мисырда Әл-Әзһәр университетында белем алган, Госмания мәктәбендә Коръән укытучы Марат хәзрәт Хафизов, онлайн мәдрәсә мөгаллиме, «Хозур» нәшрият йортының нәшрият бүлеге баш мөхәррире Ленар Хамматов та бар. Авылдагы бер генә әһәмиятле вакыйга да Шамил хәзрәт катнашыннан башка үтми. «Белем бәйрәме», «Соңгы кыңгырау» көнне генә түгел, уку елы дәвамында ул – мәктәптә һәм балалар бакчасында көтеп алган кунак. Укучылар аны үз туганнары кебек, бүләкләр белән килүен көтеп тора. Авылдагы өмәләрдә башлап йөрүче, өлкән булуына карамастан, аларда актив катнашучы да Шамил хәзрәт. Хәрәкәттә – бәрәкәт – аның тормыш девизы. Кар-яңгырмы, җил-давылмы – ул җәяүләп мәчеткә ашыга.

Роза ХӘЙРЕТДИНОВА.
Арча районы Хәсәншәех авылы

Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы
922 2022

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

«Юлчы» юлчыны дәшә

Лаеш районының Казан – Оренбург автомобиль юлында Сокуры авылы урнашкан. Авылның табигате бик матур: янында гына Мишә елгасы ага. Авылның нәкъ уртасында түгәрәк күле дә бар. Бу күл исемсез, каян көч алып, нинди сулар белән туенганы билгеле булмаса да, ул – авылның горурлыгы, ул – Сокурының визиткасы. Шуңа күрә күлнең тирә-ягында ямь-яшел, аллы-гөлле чәчәкләргә күмелгән ял паркы да бар. Сокуры Гавриил Державин туган авыл буларак та данлыклы. Покров чиркәве һәм мәһабәт «Юлчы» мәчете дә бу авылга хозурлык, күркәмлек биреп торучы төзелмәләр санала.

Бу мәчет – исеменә туры килгәнчә, юлчылар өчен туктап намаз укырга да, вәгазь тыңларга да, соңга калган юлчыларга кунып чыгарга да җайлы булган изге урын. Юлчылардан: «Бу гомер буе руслар яши торган чиркәүле авылда ничек мәчет барлыкка килде соң?» – дигән сораулар да ишетергә туры килә. Бу мәчетнең төзелүе, зур эшләр башкарып та, күләгәдә калырга яратучы, бик тыйнак һәм мөлаем Галимҗан хәзрәт Кашаповка бәйләнгән. Ул – мәчетнең иң беренче имамы.

Узган гасырның җитмешенче елларында Сокуры авылы бик алдынгы «Үзәк» («Центральный») совхозында булганлыктан, монда төрле районнардан яшьләр агыла башлый. Совхозда яшь гаиләләр өчен коттеджлар төзелә. Дүрт ике катлы унике квартиралы, заманча җиһазландырылган йортлар салына. Совхоз гөрли. Шул килүче яшьләр арасында Кашапов Галимҗан Кашаф улы да була.

Ул – тумышы белән Минзәлә районы Таулар авылыннан. 1977 елны язмыш аны алга киткән «Үзәк» совхозына, Сокуры авылына алып килә. Шул ук елны монда мәхәббәтен – Гөлсем Минвәли кызын очрата. Алар шушы көнгә кадәр мәхәббәт, сабырлык, бәхет үрнәге булган гаилә корып, өч кыз тәрбияләп үстерәләр. Хәзер инде оныклары һәм онычыклары бар.

Сокуры рус авылы булганлыктан, элек авылда татар зираты юк иде. Вафат булган мөселманнарны күрше авылларда җирлиләр иде. 1990 нчы елларда авыл советы һәм совхоз ярдәме белән татар зиратын оештыра башлыйлар. Бу эшне башлап йөрергә Галимҗан абыйга тапшыралар. «Бу эштә ярдәм итүчеләр бик күп булды», – дип искә ала ул. Шушы эшләрдән соң авылда татарлар, мөселманнар бик күп арткач, мөселман мәхәлләсе оештырырга карар кылалар. Бу вакытта намаз укырга, намазга өйрәнергә теләүчеләр дә күбәеп китә. Алар Галимҗан абый җитәкчелегендә гает намазларын укырга Казанга йөри башлыйлар. Беренче абыстайлар Сания белән Факиһә әбиләр мәҗлесләрдә Коръән укыйлар иде. Авылда беренче гает намазын клубта укыйлар, беренче азанны да шунда әйтәләр. Аннан соң гает намазларын, шулай ук җомга намазларын иске мәктәптә укып йөриләр.

Галимҗан Кашаф улы 2000 елның яз башында Казанга мәдрәсәгә укырга китә. Мәрҗани мәчете янында Мәрҗани хәзрәтләре яшәгән йортта бер бүлмәдә мәдрәсә оештырып укый башлыйлар. Ул мәдрәсәдә 2001–2002 елларда көз, кыш, яз айларында белем ала. Остазлары Габделхак хәзрәт Саматов, Алмаз хәзрәт Мөхлисов, Рөстәм хәзрәт Зиннуров була. Соңыннан ул тагын Казанның Ислам дине кабул ителүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсәсенә укырга керә. Бу мәдрәсәдә өч ел укып, диплом да ала.

2008 елның көз аенда Сокуры авылында беренче мәртәбә мәчет салына башлый һәм төзү биш ел дәвам итә. Мәчетне төзергә Гайнетдинов Азат Галимҗан улы алына. Аңа Аллаһның рәхмәтләре яусын. Ниһаять, хыялда йөргән мәчет ачыла. Барлык Сокуры мөселманнарының теләкләре кабул була. Мәчет бит ул – җәннәт өенең алды.

2013 елны мәчет ачканда зур бәйрәм булды, бик күп кунаклар килде. Ачылу тантанасына килгән кунаклар арасында мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин да бар иде. «Юлчы» мәчетенең беренче имамы итеп Галимҗан хәзрәт Кашапов билгеләнде һәм ул бүгенгәчә имам вазыйфаларын башкарып килә. Галимҗан хәзрәтнең дингә тартылуы очраклы хәл түгел. Аның әбисе Мәфтуха абыстай Коръәнне яттан белгән һәм әнисе Оркыя апа да, совет вакыты булуга карамастан, абыстай булып, Коръән укып йөргән.

Сокурының тирә-ягында аны «күңелләрне дәвалаучы» дип атап йөртәләр. Чөнки ул күңелләрне, җаннарны иман нуры белән дәвалый.

«Мәчет әле ул – яшь буынны өйрәтү урыны да», – ди Галимҗан хәзрәт. Ислам дине кануннарын үтәп яшәүче яшьләр көннән-көн арта. Дин белән кызыксынучы яшьләр кайчакта югалып калырга да мөмкин. Чөнки аралашкан саен фикер төрлелеге дә күбәя. Галимҗан хәзрәт аларга фикерләр өермәсендә адашып калмас өчен, ниләргә игътибар итәргә, динне өйрәнүне нәрсәдән башларга икәнен өйрәтә. Дингә яңа килүче яшьләргә, иң әүвәле, дөрес ният эзләү, аны дөрес итеп билгеләү кирәклеген аңлата.

Мәчетнең ишеге һәрвакыт ачык. Мәчеттә намаз укырга гына түгел, дини дәресләр, дини йолалар үткәрергә бөтен мөмкинлекләр бар.

Шулай итеп, мәчет ачылганнан бирле авылыбыз өстендә көн саен биш тапкыр азан тавышы яңгырый. Бу – иманыбызның ныклыгын дәлилли. Моңа Галимҗан хәзрәт Кашаповның керткән өлеше бик зур.

Флера ВӘЛИЕВА, 58 яшь.
Лаеш районы Сокуры авылы

Халык мәхәббәте

Сер түгел, Бөгелмә районында татарлар бик аз. Шөкер, соңгы елларда татарлар яши торган салаларда Аллаһ йортлары калкып чыкты. Халык та асылына, иманга кайта башлады.

Хәзер инде Бөгелмәбездәге һәм авылларыбыздагы мәчетләр тулы көченә эшли.

Көләч йөзле, мөлаем карашлы, тирән белемле, үз эшенә гашыйк имам – Рамил белән язмыш мәчеттә очраштырды. Рамил имам авырсынмыйча, гозеремне бик җентекләп тыңлады. Ахырдан «Гыйлем нуры» исемле зур викторинага чакырды. Менә шул «Гыйлем нуры»на барырга һәм аның белән хезмәттәшлек итәргә насыйп булды. Ул елны командабыз җиңүгә лаек булды.

Рамил хәзрәт – тынгысыз җан. Укыту, телевидениедә тапшыру алып бару, ай саен районнарга командировкалар, укытуның торышы, укучыларның белем дәрәҗәләрен өйрәнеп, белешмәләр язу... Ул – чын мәгънәсендә остаз, алыштыргысыз имам. Шуңа күрә аның «Бөгелмә авазы» газетасында басылган дини һәм әхлакый темага мәкаләләрен укучылар яратып кабул итә. Чөнки ул халык белән эшли белә.

Мәчетебез ерактан матур булып, нур бөркеп, үзенә тартып тора. Рамил мулла озак еллар халыкка игелекле хезмәт күрсәтә.

Сиринә ХӘМИДУЛЛИНА.
Бөгелмә районы Зеленая Роща авылы

Илдар Мөхәммәтҗанов

ИМАНГА ИЛТҮЧЕ РОЗА

Яңа Тинчәле авылы Буа районында иң гыйлемле авыллардан саналган. Монда заманында 5 мәчет һәм мәдрәсә эшләгән. Мәдрәсәне тәмамлаучылар тирә-як авылларга имам итеп җибәрелгән. Гыйлем бирүчеләр арасында Җамалетдин, Касыйм, Ибраһим Бикколовлар кебек мәшһүр кешеләр дә булган. Ибраһим Бикколов Томскига хәтле барып гыйлем биргән!

Хәзер авылыбызда 2 мәчет эшли, көн саен 5 вакыт намазга чакырып, азан тавышы яңгырый. Ике мәчеттә дә Гает бәйрәмнәреннән кала, башка дини бәйрәмнәр дә үткәрелә, ислам дине нигезләре, ислам әхлагы турында даими очрашулар, сөйләшүләр (лекцияләр) оештырыла. Бу очрашуларга теләге булган һәркем килә, һәм, әйтергә кирәк, халык бик теләп, яратып йөри. Аларны имамнарыбыз Илдар хәзрәт Шәрифҗанов белән Җәвид хәзрәт Алиаскаров оештыралар, ә үткәрүче абыстайларыбыз – Зәүҗия апа Төхфәтуллова, Әкълимә апа Гайзатуллина, Роза Хәсәнова.

Район үзәгендә мәдрәсә ачылгач, күп кешедә белем алу теләге барлыкка килде. Тик Буа ерак, бөтен кеше дә анда барып укый алмый. Башта мәдрәсәдән укытучылар чакырып, хәреф танырга, намаз укырга өйрәндек. Тик хәрефләрне кушып уку бик авыр, тәҗвид кагыйдәләренә туры китереп уку тагын да катлаулы! Ә укыйсы килә! Шул елларда гомер буе авылыбызда фельдшер булып эшләп лаеклы ялга чыккан Роза Җәгъфәр кызы Хәсәнова Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керде. Аны анда Аллаһ кушуы белән белем алуга хирыс булуы, омтылышы илтте. Укуының икенче елында үзенә яңа пенсиягә чыккан, чагыштырмача яшь хатын-кызлар төркеме җыйды. Өлкәннәр төркеме инде яхшы гына укый башлаган иде, алар Коръән укуны аерым дәвам иттеләр. Мәчеттә белем алуыбызны Буа мөхтәсибәте һәрвакыт хуплады, баштагы елларда аннан мөгаллимнәрне чакырып, укуыбызны тикшертеп, файдалы киңәшләрен алып тордык.

Роза Җәгъфәр кызы белем бирүне мәдрәсә программасы нигезендә алып барды. 4 ел буена ислам дине нигезләре, фикһ, әхлак һәм Коръән уку дәресләре үткәрде. «Мөхәммәдия»дә алган белемнәрен үзе дә ныгытты, безгә дә өйрәтте. Шушы курсларны бетергән 7 хатын-кызыбыз бүген Буа мәдрәсәсен дә тәмамлап, диплом алу бәхетенә ирештеләр. Роза Җәгъфәр кызы бер төркем ир-егетләребезгә дә белем бирде. (Авылда дипломлы дин белгече – мөгаллимә булгач, Буа мөхтәсибәте хатын-кызга ир-атларны укытырга рөхсәт бирде.) Хәзер алар да Коръән укыйлар, авыл мәчетләребездә азан әйтәләр.

Роза ханым кечкенәдән Коръән сүзләрен әбисеннән ишеткән. Ул балачактан ук ятим калып, әбисе тәрбиясендә үскән. Буа медицина училищесын тәмамлап, шушы авылга килен булып килеп, гомер буе кешеләрнең саулыгын кайгыртып яшәде. Авыл халкының олуг хөрмәтен яулады. Хәзер инде рухи саулыгыбызны саклап, Аллаһ кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып, дөрес итеп яшәргә өйрәтә. Үзе дә һаман гыйлемен арттыру өстендә эшли, хаҗ гамәлен үтәп кайтты. Кешеләрне дингә чакырырга, белгәннәреңне сөйләргә була. Иң авыры – инде үсеп җитеп гаилә корган, характерлары формалашкан балаларыңны үзеңнең шәхси үрнәгеңә ияртүдер. Монысын бөтен кеше булдыра алмый, көчле шәхес булу сорала бу эштә. Роза ханым исә бөтен гаиләсен ияртә алды үзенә! Балалары, кияү-киленнәре намазга да бастылар, укырга да өйрәнәләр.

Бу дөньяда ничек уңышка ирешергә, бәхетне, күңел тынычлыгын ничек табарга – барысын да уку, гыйлем алу сәбәпле беләбез. Аллаһы Тәгаләнең беренче әмере «Укы!» дигән сүз булган. Үзебезнең татар муллалары, галимнәре берничә тел белгәннәр, шул телләрдә китаплар язып калдырганнар. Китап уку – татар милләтенең төп үзенчәлеге. Ислам өммәтен, милләтебезне алга җибәрү өчен бик күп укырга кирәк. Ул белем файдалы гыйлем булырга тиеш. Коръәндә дә: «Иман китереп һәм белем иясе булган мөэминнәрне Аллаһ дәрәҗәләргә күтәрер», – диелә. Менә шуңа күрә бабайларыбыз омтылган белем юлына без дә омтылабыз.

Мәчетнең күрке – анда халык килүе. Әлхәмдүлилләһи, мәчеткә йөрүчеләр саны һәр елны артып тора. Бигрәк тә

изге рамазан аенда яшьләребезнең өлкәннәр белән бергәлектә гамәл-гыйбадәтләрне үтәүләре күңелгә шатлык өсти, киләчәккә өмет уята.

Сәфинә АЛИУЛЛОВА.
Буа районы Яңа Тинчәле авылы

Язучы фикере



Марат КӘБИРОВ

Бир син миңа...

Безнең яклар матур. Хәтта тәрәзәмнән генә карап утырсаң да хозурланып туймас матурлыкка юлыгасың. Тәзек йортлар. Шул йортларның бакчаларында серләшеп утырган агачлар. Яфраклар җемелдәве. И, ул яфракларны гына да бер төрле түгел бит әле аның, төрле-төрле төсләргә кереп, төрле тизлектә, төрле чагылышта җемелдиләр. Ихатаңа чыгып утырсаң – яшел чирәм. Алар арасында әрсезләнеп үскән чәчәкләр. Хәтта коймa буенда уталып бетмичә калган кычыткан ботагы да үзенчә ямь сибеп утырган була. Ә инде бакчаңа күз салсаң… Аларның һәр чәчәге шигырь кебек тоела, үзең утырткан, үзең карап үстергән матурлык бит. Мин хәтта шигырьләремне дә алай үстермәдем, ә чәчәкләрне… һәр таҗында минем өлешем бар, һәр нурында мин чагылган сыман.

Тау башында үләннәр тибрәлә. Җәйнең ягымлы җилендә дулкын-дулкын булып тирбәләләр. Мин тауларның агачлыкларын ярата идем, әле менә боларны да бер могҗиза шикелле. Тау башында үскән диңгез кебек. Яшел диңгез. Җилләр агышына карап дулкыннары берчә талгын, берчә көчәеп төрле төсләргә керә. Дулкыннар дулкынланырга мәҗбүр итә. Дулкынланам. Мин үземне гади бер дөньяда түгел, ә оҗмахның кайсыдыр өлешендә яшәгән кебек тоям.

Шушы матурлыкны бөтен тулылыгында кабул итәргә теләп, ишегалдындагы яшел чирәмгә сузылып ятам. Кулларымны җәям. Күзләр кысыла. Баш очында зәп-зәңгәр күк йөзе. Аның бизәкләре булып ак болытлар йөзә. Болытларда да кояш бар, кояш нурлары күзне чагылдыра. Керфекләрне ачып-йомып алам. Күңелем назлы җил сарыла.

Күңелдә рәхмәт тойгысы. Яшәгәнлегемә. Шундый матурлыкларны күрә алуыма. Болар барысы да – Ходайныкы. Ходай аны миңа бушлай бирә. Билет алуымны да, абоненты булуымны да сорамый. Аңа минем социаль статусым да, кәефемнең нинди булуы да кирәкми. Тудырган ул шундый матурлыкны. Минем бары тик шуны күрүем һәм кадерләвем генә кирәк. Җаныма сеңдерүем. Әгәр шуны кабул итә алсам, ул матурлык миндә дә болытларда чагылган кояш нуры шикелле аерым бер матурлык булып балкыячак.

– Әй, Ходаем… – дип пышылдыйм мин шундый хозурлыктан күңелем тулып, – бир син миңа…

Һәм тукталып калам. Нәрсәседер дөрес түгел кебек тоела. Дөрес түгел, әлбәттә!

Нәрсә сорыйсың син?

Ни дип теләнәсең?

Биргән бит инде ул. Матурлыгын да, шул гүзәллекне сыйдыра алырлык йөрәкне дә. Матурлык турында уйлый алырлык сәламәтлек тә биргән. Тагы нәрсә кирәк инде сиңа?

– Акча… – дигән уй йөгереп үтә, тик мин аны куып җибәрергә ашыгам. Әйе инде, ул да хаклы, уйлаганнарымны тормышка ашырып бетерү өчен акча кирәк. Тик мин эшләп торам. Акча ул вокзалдагы пассажир шикелле, килә дә китеп тә бара. Ә матурлык бүтән… Шушы мизгелдә мин тойган, мин күрә алган матурлык ул гомер буе миндә яшәячәк. Гомерләрнең авыр мәлләренә баш идерми торган көч булып.

– Әй, Ходаем…

Ә мин аннан нәрсә сорарга да белмим. Ә нәрсәдер сорыйсы килә. Күңелнең шундый ләззәтле мәлендә Ходайдан берни дә сорамый калсаң дөрес булмас кебек. Тик шундук икенче дулкын бу теләкне юып төшерә:

– Теләнче! – һәм акылның бер үгете булып өстәп куя: – Беркайчан да теләнче булма!

Дөрес инде ул. Теләнче булырга ярамый. Моңа кадәр беркемнән берни көтмичә үткәрдем бит инде гомеремне. Моннан соң да көтәргә ярамый. Үзең эзләргә, үзең табарга кирәк. Бүтәннәрдән көткән саен, эзләү сәләте кими, табышлар юкка чыга.

Ә Ходай ул барысын да биргән. Тик күрергә һәм үреләп ала белергә генә кирәк. Аннан берни дә сорарга кирәкми. Швед рестораннындагы шикелле бит инде монда барысы да. Ризык-ниґмәте дә, матурлыклары да. Күпме телисең, шулхәтле аласың. Тұлисең дә инде. Кайчак сәламәтлегең, кайчак гомерең, кайчак бүтән вактояклар белән. Ләкин эш синең алуыңда да, туләвеңдә дә түгел. Эш синең сөенә белүеңдә.

Ходай биргән шушы матурлыкларга, шушы муллыкларга, шушы оҗмахка сөенә беләсең, ул үзе дә сөенер кебек тоела. Шуларны аңлагач, мин үземне кабат бәндә итеп тоям. Бәндә. Чикле һәм мескен җан иясе. Чөнки мин:

– Әй, Ходаем, бир син миңа… – дип сорыйм.

Әле үземә бирелгәннәренең барысын да татып-тоеп өлгермәгәнмен, мин тагын нидер сорыйм. Запаскамы? Запас нигә кирәк? Бөтен галәм җирдә минем өчен эшли, бөтен дөнья – минем запасым. Ләкин миңа үземнеке кирәк. Миңа гына була торган запас. Нигә соң ул? Белмим. Бәлки, кирәкмидер ул. Кирәкми, әлбәттә. Ләкин шундый самими мизгелдә нидер сорыйсы килә. Без бит инде гади кешеләр, үзебездән аз гына дәрәҗәлерәк кешеләрдән дә нәрсәдер өмет итеп, бәлки, берәр файдасы тияр дип өлтерәп тора торган бәндәләр. Ә монда Ходай! Ничек сорамыйсың? Бернигә мохтаҗлыгың булмаса да, нәрсәдер сорарга кирәк. Мизгеле шундый. Ул мизгелне кулдан ычкындырырга ярамый.

– Әй, Ходаем, бир син миңа…

Шулай дим дә бераз уйланып торам. Һәм өстәп куям. Зур канәгатьлек белән. Чөнки мин ул кирәкле сүзне таптым сыман.

– Син яраткан шушы хозурлыкка сөенеп яши алырлык гомер бир…

БЕЗ КЕМНӘН ОЯЛАБЫЗ?

МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЫ ИРАДА ӘЮПОВА МӘДӘНИ ЯҢАЛЫКЛАР БЕЛӘН ТАНЫШТЫРДЫ

mincult.tatarstan.ru

Без ни өчен милли киемебездән оялабыз? Татарча опера кайда яңгырарга тиеш? «Тукай картасы» кемгә тәтер? Мәдәният министрлыгы быел да җәйнең матур көнендә журналистлар белән очрашу уздырды. Бу юлы ул фикер алышу, теләктәкъдимнәр тыңлау форматында үтте.

Очрашу Фешин исемендәге Казан сәнгать көллиятендә узды. Сентябрьдә монда Россиядә беренче «Креатив индустрияләр мәктәбе» ачарга ниятлиләр. Көллият директоры Ольга Гыйльметдинова сүзләренә караганда, мәктәпкә 12–17 яшьлекләр кабул ителә. «Дүрт төркемгә 80 бала кирергә уйлыйбыз. Мәктәпкә укырга керү бушлай. Алай гына да түгел, укырга сынауларсыз алачакбыз. Ягъни беренче булып гаризаны кемнәр бирә, шулар укый алачак», – диде ул.

Мәктәптәге курслар быел дүрт юнәлештә алып барылачак: виртуаль чынбарлык, дизайн, анимация һәм мультипликация, фото һәм видео. Ә киләсе елдан исә бөтенләй яңа – фэшн-дизайн һәм күн эшкәртү юнәлешләре дә эшли башлаячак.

Традициягә тугрылык

Матбугат очрашуы милли кием, милли мода турында фикер алышудан башланды.

– Традицияне консерватизмлык дип атаучылар белән бөтенләй дә килешмим. Ул, киресенчә, җәмгыятьтәге, яшәештәге үзгәрешләргә бик тиз җайлаша. Әгәр без традицияләрне консервацияләгән булсак, берничә дә сакланмаган булыр иде. Дөнья бит безгә кадәр дә үзгәргән. Татар милли костюмын гына карагыз: ул бит һәр вакыт бер төрле генә булмаган. Ләкин бер генә булса да элементы, үзенчәлеге гасырлар буена сакланган. Бүген без әлеге өлкәдә яңалыкны, традицияләргә нигезләнеп, яңадан кулланышка кертү максатын күз уңында тотып эшлибез.

Узган елларда Саха (Якутия) Республикасында якут халкының Ысыах бәйрәмендә булдык. Бәйрәмдә 200 меңнән артык кеше катнашты. Күз алдына китерегез: Ысыахка килгән бар кеше диярлек үзләренең милли киеменнән иде. Әйе, ул костюмнарны бер гасыр элеккеләре белән чагыштырып булмый, алар заманча итеп эшләнгән. Ләкин һәркемнең өстендә милли кием булуы күренеп тора.

Төбәкләрдәге менә шундый чаралар җитештерүчеләргә бик ярдәм итә. Шул исәптән, матди яктан да. Ысыах мисалында гына карасак та, алар кигән заманча милли киемнәрне үз осталары тегә бит. Менә шушындый бәйләнеш кирәк. Шул очракта традицияләрне саклый һәм аларны көндәлек тормышка яраклаштыра, киң кулланышка кертә алачакбыз, – дип сөйләде Ирада Әюпова.

Ә нигә бездә алай түгел? Министр сүзләренчә, бу үзебезне иркен тота алмауга бәйле.

– Бездә халык үзен күрсәтүдән ояла. Милли кием кию түгел, бәйрәмнәрдә күңел ачудан да тартынып, куркып, читтә утыралар. Башкалар күрсә, нәрсә әйтерләр? Рухи азатлык хисенә бәйледер бу. Билгеле, бар кешегә дә милли кием кидереп бетереп булмас. Моның өчен тулы бер индустрия булдырырга кирәк. Мөмкинлекләр бар, эшлисе генә калды.

Телне имтихан саклыймы?

Билгеле булганча, быел татар теленнән БДИны бер генә укучы сайлады. Мәдәният министрлыгы моның өчен җаваплылык тоямы икән, дип кызыксынды журналистлар.

– Мин, гомумән, БДИны бик өнәмим. Имтихан ул – имтихан гына. Укучы нинди фәннән имтихан бирәсен киләчәктә нинди һөнәр, кайсы уку йортын сайлавыннан чыгып билгели. Татар телен саклауны БДИга бәйләргә кирәкме икән ул? Тел бит турыдан-туры мохиткә бәйле. Без татар телен саклап кала алырдай мохит турында уйланырга тиеш. Әйтик, һәр укучы математика һәм рус теленнән имтихан тапшыра. Ләкин бу бит әле бездә искиткеч грамоталы кешеләр һәм шәп математиклар күп булачак дигән сүз түгел, – дип җавап бирде министр.

Татарча опера кемгә кирәк?

М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры сәхнәсендә узган сезонда татарча опера 11 мәртәбә куелган. Очрашуда бу санны аз диючеләр дә, җитәрлек дип санаучылар да булды.

– Бу – шактый катлаулы мәсьәлә, аңа төрле яклап карарга була. Финанс ягын алыйк. Яхшы, сыйфатлы операны сәхнәдә күрсәтүнең нинди чыгымлы эш булуы инде билгеле. Бу чыгымнарның 30 процентын тамашачыларга сатылган билетлар каплаcа, калганы – дәүләт карамагында. Әгәр без хәзер дәүләт заказын арттырабыз икән, бюджетны да арттырырга туры киләчәк.

Икенчедән, татар операсын Татарстанда ничә мәртәбә күрсәтүләре турында түгел, дөнья аренасына чыгару турында уйланырга кирәк. Милли мәдәниятебезне үзебездә ябылып кына саклап булмый. Татар операсы Казан сәхнәсендә генә яңгырарга тиеш түгел.

Моннан тыш, татарча операга татар телен яхшы белгәнгә генә йөрмиләр. Башка телләрдәге опера сәнгате белән дә шул ук хәл. Һәм, гомумән, татарлар татар операсын гына тыңларга тиеш дигән сүз түгел, – дип аңлатты Ирада Әюпова.

«Тукай картасы»

Татарстан Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгатьне үстерү буенча республика советы утырышында үзебездә дә «Пушкин картасы»на охшаш проект булдыру турында сөйләшкәннәр иде. Ирада Әюпова сүзләренчә, әлеге проект – халык юллаган тәкъдим. Аны үзебезчә, матур итеп, «Тукай картасы» дип атамакчылар.

– Билгеле булганча, «Пушкин картасы» – яхшы финанслаган проект. Ягъни һәр сатып алынган билет өчен мәдәният учреждениеләренә акча килә. «Тукай картасы» да шушында охшаш механизм буенча эшләячәк. Әлегә без аны дәүләт учреждениеләренә квоталар бүлеп бирел, билгеле бер чаралар исемлеген булдырып тормышка ашырырга әзерләнәбез. «Тукай картасы»н социаль яктан якланмаган категориягә караучылар куллана алыр дип уйлыйбыз.

Моннан тыш, министр «Пушкин картасы»ның да аудиториясен киңәйтергә ниятләүләре, бу юнәлештә федераль дәрәҗәдә сөйләшүләр алып барулары турында әйтте.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КЫЯРНЫ КЕМ АШАГАН?

Тормыш кыйпылчыклары

Кибетләрдә ел әйләнәсе яшел кыяр өзелмәсә дә, килешәсез дер, үз бакчаңда, үз теплицаңда өлгергән беренче кыярны һәркем сабыйларча көтеп ала. Аның тәме дә башка кебек. Безнең үзебездә элеккедән калган гадәт: беренче кыярны бүлеп авыз итәбез. Бала чакта әле такмазасын да әйтә идек: «Иске авыз, яңа аш, чирем-чорым, миннән кач!» Авырулар китәсенә ышанып әйтә идек.



vk.com

Әле бит ул чакта хәзерге кебек кибеттә өеләп тормый, кыяр вакыты бер генә. Анда да әби мәрхүмә, орлыкка дип, беренче кыярларны ашамаска куша, билге – кечкенә ак чүпрәк кисәге бәйләгән таякчык кадап куя. Безме соң инде сабыр итә торган! Ул таякчыкларны икенче урынга күчереп куя идек тә… Хәер, сүзем бит балачак шуклыклары, кыярлары турында түгел.

Быел яз соңга калып килсә дә, уңлап төп кыяр җыштылмаган теплицада да ничектер салкыннарга биреш ми айбат кенә үсте. Кыярларын ашый башлаганга да шактый инде. Үзебез генә дә түгел, быел теплицага бер «кунак» тә ияләште. Гадәттәгечә, беренче кыярны көн дә карап үстердек. Тагын аз гына үссен инде, барыбыз авыз итәрлек булсын, янәсе. Көннәрдән бер көнне әлеге кыяр юкка чыкты. Сабагында төбе һәм яңашәдәге җирдә туралган кисәкләр генә калган. «Берәр корт ашагандыр», – диде өйдәгеләр. Корт ашаганга түгел, тешләп, кимереп ашаганга охшаган, мин әйтәм (күңелгә сукыр тычкан түгелме икән дигән уй килде). Берничә көннән зурая башлаган ике кыярның сабакта төбе генә исәнен калды. Аннан тагын. Ваклары кала, нәкъ менә иң зурларына «бәйләнә» мәлгунь. Бер авылдашыма зарланган идем, «Күршегез Рәдифә дә кыярларны нәрсәдер ашый, бер кыяр ала алган юк дип әйтте», – ди.

Бөтен җиләк-җимешне күз ачып йомганчы юк итә торган миләш чыпчыклары «дус» безнең бакчалар белән. Кыярга да тотындыларымы икәнни дисәк…

Бер көнне кич Рәдифә кергән: «Зур сары мәче сезнеке түгелме? Монда кереп кенә юганды. Телен ялый-ялый теплицадан чыгып китә. Кыярны шул мәче ашый икән бит… » «Безнеке түгел, бездә дә еш кунак ул», – дим. Эзли торгач, хуҗасын тапкан Рәдифә. Каршы як күршеләренеке икән. «Кыяр гына түгел, чи бәрәңге дә ашый әле ул», – дигәннәр.

Авыл мәчесе дигәч, безнең күз алдына мыш-мыш килеп сөт эчкән, ит-май ашый, сөяк кимерә торган мәче килә. Тик хәзер алар да шактый үзгәрде шул. Тәм-томны бик яраталар. Моннан күп еллар элек ул чакта Төмәндә яшәгән апамның малайлары пешкән кызыл чөгендер, тозлы кыяр, свежий колбаса гына ашый торган (ул чакта авылга колбаса кайтмый, Балтачтан алып кайтасы, теләсә нинди ашамый иде әле ул, әйбәтен бирегез, дип сорап ала идем) песи баласына бөтен тирә-күрше аптыраган идек. Хәзер әнә саланыкылар да кимен куймый. Безнекеләр, мәсәлән, бишәүләп тезелешеп, көтү каршына чыга. Анда утыручы апаларның көнбагыш ашаганын белә. Инде алар да безнең песиләрнең симәнке корты икәнен белә. Лапас ишегеннән күренүгә, килегез, әйдә, дип чакырып сыйлыйлар. Бирмәсәләр, сорап та ала мәчеләребез. Тик безнекеләр әдәплерәк, тегe сары мәче кук сорамый гына, шыпырт кына ашап качмый…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7057 данә
Гомуми тираж – 16016 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 291

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкаләләр авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Кулкереп басуры өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+